...БЕЗ “ТУГАН ТЕЛ”НЕ
ИҖАТ ИТКӘН ТУКАЙЛЫ...
МӘҢГЕ ЯШЬ“ӘЛМӘНДӘР”НЕ
ИҖАТ ИТКӘН ТУФАНЛЫ
ХАЛЫК...

# ТАТАРСТАНЫҢ ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ, КҮРЕНЕКЛЕ ДРАМАТУРГ, ПУБЛИЦИСТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ ТУФАН ГАБДУЛЛА УЛЫ МИҢНУЛЛИН





1935 ЕЛ. 25 АВГУСТ. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘРӘТХУҖА АВЫЛЫНДА ИГЕНЧЕ ГАБДУЛЛА ГАИЛӘСЕНДӘ ТУПЫРДАП ТОРГАН ИР БАЛА ДОНЬЯГА АВАЗ САЛА...

“....ДӨНЬЯГА КИЛДЕҢ, САБЫЕМ! БУ ҖИҺАННЫҢ БАР ГҮЗӘЛЛЕГЕН, БАР МАТУРЛЫГЫН ТОЙ!... ХАЛКЫБЫЗНЫН КӨЙ – МОҢНАРЫН САНДУГАЧЛАР – ТУРГАЙЛАР МОҢЫ АША ҮЗ ИТ! ХАЛКЫҢ БЕЛӘН ГОРУРЛАНЫРГА ӨЙРӘН...

# ТОРМЫШ БАСКЫЧЛАРЫ БУЙЛАП:

- **1952-1956 еллар:**
- урта мәктәпне тәмамлый;
- Туган төбәгендәге Олы Кариле һәм Кама Тамагы авылларында – хисапчы;
- Казанда бухгалтерлар әзерләү курсларын тәмамлый;
- Комсомол юлламасы белән чирәм җирләргә китә - Казахстанның Кустанай өлкәсендәге бер совхоз кооперациясендә баш бухгалтер.

- **1956 – 1961 еллар**
- Мәскәүдә М.С. Щепкин исемендәге Театр училищесында укый.
- **1961 – 1964 еллар**
- Минзәлә драма театрында актер;
- Казанда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер.

# ТОРМЫШ БАСКЫЧЛАРЫ БУЙЛАП:

## 1964 – 1967 ЕЛЛАР

- Казан телестудиясендә өлкән мөхәррир
- “Чаян” журналы редакциясендә бүлек мөхәррире

## 1968 – 1975 ЕЛЛАР

- Язучылык хезмәтендә.

## 1975 – 1977 ЕЛЛАР

- Мәскәү СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларында укый.

# ДРАМАТУРГИЯ БУЙЛАП ТӘҮГЕ АДЫМНАР



# ДРАМАТУРГИЯ БУЙЛАП ТӘҮГЕ АДЫМНАР:

| ЕЛ | ДРАМА ӘСӘРЕНЕҢ ИСЕМЕ | КУЕЛГАН ТЕАТР БИНАСЫ |
|---|---|---|
| 1962 | “Безнең авыл кешеләре” (3 пәрдәле комедия) | Минзәлә драма театры |
| 1967 - 1969 | “Азат” (пьеса - әкият) | Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры |
| | “Күрше кызы” | Әлмәт дәүләт театры |
| | “Миләүшәнең туган көне” | Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры |
| | “Нигез ташлары” “Йөрәк янар өчен бирелгән” | ТР Күчмә театры(хәзерге К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры). |



1963 – 1999 ЕЛЛАР АРАСЫНДА Г. КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ Т. МИҢНУЛЛИННЫҢ 26 ПЬЕСАСЫ БУЕНЧА СПЕКТАКЛЬ УЙНАЛА.

# АЕРУЧА УҢЫШ КАЗАНГАН ӘСӘРЛӘРЕ


- “Әлдермештән Әлмәндәр”
- “Ай булмаса, йолдыз бар”
- “Диләфрүзгә дүрт кияү”
- “Әниләр һәм бәбиләр”
- “Кырларым-тугайларым”
- “Үзебез сайлаган язмыш”
- “Нигез ташлары”
- “Монда тудык, монда үстек”
- “Ир-егетләр”

# Т. МИҢНУЛЛИН — ПЬЕСАЛАРЫ ИЛЕБЕЗ СӘХНӘЛӘРЕНДӘ ИҢ КҮП УЙНАЛА ТОРГАН ТАТАР ДРАМАТУРГЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ.

- Башкортстан театрларында («Диләфрүзгә дүрт кияү», «Үзебез сайлаган язмыш», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Кырларым-тугайларым» һ. б.);
- Үзбәкстанның Мөкыйми исемендәге дәүләт музыкаль театрында («Диләфрүзгә дүрт кияү») ;
- Хәмзә исемендәге Үзбәк дәүләт академия театрында («Әлдермештән Әлмәндәр») ;
- Шкетан исемендәге Мари дәүләт театры - Басарганов исемендәге Калмык дәүләт драма, Мурманск, Новокузнецк, Әстерхан, Горький, Мичурин һ. б. шәһәрләрнең рус драма театрлары - «Әлдермештән Әлмәндәр»-
- Дагыстанда С.Стальский исемендәге Лезгин һәм Ә. Капиев исемендәге Лак дәүләт драма театрлары- «Ай булмаса, йолдыз бар»

# ТУФАН МИҢНУЛЛИН БАЛАЛАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ

- “Азат”
- “Гафият турында әкият”
- “Айга сәяхәт”
- “Айбулат”
- “Авыл эте Акбай”
- “Акбай һәм сарык малае”
- “Акбайның яңа мажаралары”
- “Акбай һәм Кыш бабай”
- “Акбай нигә күңелсез”
- “Иптәш командир”
- “Кайда хаклык, кайда дөреслек”
- “Бик бүлтәймә, Бультерьер” һ.б.


МӘЙДАНЧЫК
Балалар өчен кушымта
Туфан МИҢНУЛЛИН
Гашыйк буласым килә
(Ике пәрдәле тамаша)


АВЫЛ
ЭТЕ
АКБАЙ

# УҢЫШ БАСКЫЧЛАРЫНДА

- Т. Миңнуллин «Нигез ташлары» комедиясе һәм «Үзебез сайлаган язмыш» драматик хикәясе өчен 1974 елда Татарстанның М. Җәлил исемендәге Дәүләт премиясенә, «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәре буенча Әлмәт драма театрында куелган спектакль өчен 1979 елда Татарстан АССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә һәм Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен, режиссер Марсель Сәлимҗанов һәм баш рольне башкаручы артист Шәүкәт Биктимеров белән бергә, 1979 елда РСФСРның К.Станиславский исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Татар театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа “Татарстан АССРның (1978) һәм РСФСРның (1984) атказанган сәнгать эшлеклесе” дигән мактаулы исемнәр бирелә, 1984 елда исә ул «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.

# ГАИЛӘДӘ, ЭШТӘ, ДУСЛАР ҺӘМ ТУГАННАР АРАСЫНДА










# ТЕАТР ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ...



# ТУФАН ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ҖАНЛАНЫШЫ







# ТУФАН ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ҖАНЛАНЫШЫ













**ТАТАРСТАНННЫ ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ, КҮРЕНЕКЛЕ ДРАМАТУРГ, ПУБЛИЦИСТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ ТУФАН ГАБДУЛЛА УЛЫ МИҢНУЛЛИН ТАТАР ХАЛКЫ КҮҢЕЛЕНДӘ ҖУЕЛМАСЛЫК ЭЗ КАЛДЫРДЫ**














**Т. МИҢНУЛЛИН ӘДӘБИ ИҖАТЫН ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЭШЧӘНЛЕК БЕЛӘН БӘЙЛӘП БАРДЫ. УЛ БЕРНИЧӘ ЕЛ ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНА ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТТЕ, 1984 ЕЛДА ТАТАРСТАН АССР ЮГАРЫ СОВЕТЫНА ДЕПУТАТ ИТЕП САЙЛАНДЫ. ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ Х КОРЫЛТАЕНДА (МАЙ, 1984) Т.МИҢНУЛЛИН БЕРЛЕК ИДАРӘСЕНЕҢ РӘИСЕ ИТЕП САЙЛАНА. 1969 ЕЛДАН УЛ - СССР ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ӘГЪЗАСЫ. УЛ -  ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ДЕПУТАТЫ БУЛДЫ.**

**ТУФАН КЕБЕКЛӘР БУЛГАНДА ТАТАР ХАЛКЫ, ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ, ТАТАР ТЕАТРЫ ЯШӘР... ЯҢА СӘХНӘ ЙОЛДЫЗЛАРЫ КАБЫНЫР...**










ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ТЕАТРЫ
ГАСТРОЛЬЛӘРЕ

# ТР АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИТРӘЙ АВЫЛ КИТАПХАНӘЧЕСЕ

# СИРАЗИЕВА ГӨЛӘНДӘМ ФӘРИТ КЫЗЫНЫҢ ЭШЕ